

Изге бәйрәмебез – Корбан гаете Золхижжә аенын унынчы конендә билгеләп vтелvче бу кон быел 20 июльгә туры килде. Сишәмбегә каршы тондә мәчетләрдә ин элек бәйрәм вәгазе сойләнде. Ул иртәнге дvртенче яртыда башланды. Иртәнге дvрттә Гает намазы укылды.
Коронавирус белән бәйле вазгыятьне истә тотып, гает конне мәчетләргә кvп дигәндә 100 кеше генә керде. Калганнар исә бәйрәм намазын урамда укыды. Бу хәбәр шәһәр һәм зур авыл мәчетләренә кагыла. Ә хәзер, Мордовиядәге мосел-маннарыбыз һәр бәйрәм алдыннан, башка чакта да зиратта яткан кардәшләренен каберлекләрен жыеш-тырып торалар, догасын укыйлар һәм гает коннәрендә туганнары яткан изге урынга барып кайталар. Ә менә бәйрәм алдыннан бигърәк тә. Шулай, Кадошкино районы Большие Поляны авылында зиратнын эчен тулысынча тәртипкә Рафик Әхмәт улы Долотказин, Ринат Равил улы Долотказин, Равил Хәсән улы Зайкин, Рәшит Шәvкәт улы Зайкин китергәннәр; юллардан vләннәрне чапканнар, комачаулаган зур-зур агачларны кисеп машинага тутырып зираттан чыгарып ташлаганнар һәм башка шундый эшләрне, субботник vткәнен котмичә, башкарганнар.
Ярдәмчел, шәфкатьле, игелекле, vз авылын чын кvнелдән яраткан татарларыбыз булганга, донья ямләнеп китә. Тагы бер мисал. Кvптән тvгел Темников районы Зур Татар Караево авылына алып баручы юлнын ун ягында кызыл кирпечтән тозелгән корылма барлыкка килә: моселман ярымайлары булган таш баганалар, анын уртасында - авылнын исеме һәм кунакларны татар һәм рус телләрендә сәламләv язылган. Авылнын символы – алгы аякларына кvтәрелгән атлар бик нәтижәле кvренә. Әлеге конструкция очен мәйданчык бетонланган һәм тротуар плиткасы белән дә тvшәлгән.
Бу эш vз авылын ихластан яратучы Халил Равил улы Кичемасовнын. Биредә анын бабасы, әтисе, ул vзе һәм анын балалары туган. Анын кая да булса китәргә дип беркайчан уйлаганы да булмаган. Кайда туган, шунда кирәк тә булган. Ана 35 яшь. Анын vз гаиләсе, хужалыгы бар.
Авылга керv урынын тәртипкә китерv кvнелнен гvзәл мизгеле. Һәм Халил Равил улы моны чын кvнелдән, кин колач белән vз акчасына башкарган. Һәр тос монда эчтәлеккә ия. Моселманнар очен кызыл - изге, магик, зур тормыш коче булган тос дип санала. Яшел - тере табигать тосе. Алтын дан, уныш, байлыкны символлаштыра.
Игелекле, шәфкатьле, михербанлы эшләр башкарыйк, дуслар!

Н.ХӘЛИЛ